КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 553

Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып төзелгән капиталь ремонт фонды акчасы исәбеннән финанслана торган һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару санына керә торган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яки) эшләр башкаруны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы $1^1$ өлеше, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып төзелгән капиталь ремонт фонды акчасы исәбеннән финанслана торган һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару санына керә торган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яки) эшләр башкаруны расларга.
2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 май, 553 нче
карары белән расланды

Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып төзелгән капиталь ремонт фонды акчасы исәбеннән финанслана торган һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару санына керә торган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яки) эшләр башкару

| Т/с | Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр | Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчасы исәбеннән күрсәтелүе һәм (яки) башкарылуы финанслана торган һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау хезмәтләре һәм (яки) эшләре санына керә торган хезмәтләр һәм (яки) эшләр (кертеп, әмма чикләмичә) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | Аерылып бара торган торба үткәргечләрне һәм стоякларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Бик арматурасын, шул исәптән стояклардан фатирларга керә торган урыннарда алмаштыру, кую |
| | | Булмаганда (техник мөмкинлек булганда) циркуляция линиясен булдыру |
| | | Торба үткәргечләрне һәм арматураны изоляцияләү |
| | | Гомуми файдалану урыннарында торба үткәргечләрне, су бирү җайланмаларын алыштыру |
| | | Гомуми файдалану урыннарында санитар-техник приборларга су килә торган сыгылмалы көпшәләрне алыштыру |
| | | Сөлге киптергечләрне (шул исәптән регистрларны) алыштыру, бик арматурасын куеп, вертикаль буйлап тоташ су бирү стоягына тоташтыру (стояклардан фатир эчендә аерылып китә торган урыннарда җайга салына торган бик краннары булмаган очракта) |
| | | Басымны арттыра торган насос җайланмаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, кую |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | Кайнар су әзерләү һәм бирү комплексларында кайнар су параметрлары көйләгечләрен, җылылык алмашу приборын, бойлерларны, насос җайланмаларын һәм башка җайланмаларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, кую |
| | | Коммуналь ресурсларны исәпкә алу һәм җайга салу үзәкләрен урнаштыру өчен техник бүлмәләрне торгызу яки булдыру |
| | | Янгын суүткәргече системасын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, кую |
| | | Техник идән астында яки беренче катның идәне астында торба үткәргечләрне демонтажлаганда, монтажлаганда, яңадан торгызганда, алыштырганда идәннәрне куптарып алу һәм, антисептика белән эшкәртеп, яңадан җәю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре уза торган урыннарда конструкцияләрне сүтү һәм яңадан җыю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре керә торган һәм бина фундаменты белән кисешкән урыннарны герметизацияләү |
| | | Гидравлик сынаулар |
| | | Җир белән тоташтыру чыбыклары контурын демонтажлау, монтажлау, яңадан булдыру, урнаштыру |
| | | Потенциалларны өстәмә тигезләү системасын демонтажлау, монтажлау, торгызу, шул исәптән фатирлардагы ванналарны җиргә тоташтыру |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 2. | Су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | Канализация торба үткәргечләре системаларын алыштыру |
| | | Җыелма тармаклана торган (горизонталь) торба үткәргечне һәм стоякларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Канализация торба үткәргечләре системаларында бик клапаннарын урнаштыру |
| | | Җылыткыч куеп, пычрак суларны бетерү торбаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Гомуми файдалану урыннарында трапларны һәм душ поддоннарын алыштыру |
| | | Гомуми файдалану урыннарындагы душ бүлмәләрендә |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | идәнгә һәм стеналарга гидроизоляция урнаштыру |
| | | Гомуми файдалану урыннарында санитар-техник приборларны демонтажлау һәм монтажлау |
| | | Гомуми файдалану урыннарында санитар-техник приборларны (унитазларны, югычларны, раковиналарны, ванналарны) алмаштыру |
| | | Эчке су агып төшә торган торба элементларын алыштыру яки ремонтлау |
| | | Техник идән астында яки беренче катның идәне астында торба үткәргечләрне ремонтлаганда, алыштырганда идәннәрне куптарып алу һәм, антисептика белән эшкәртеп, яңадан җәю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре уза торган урыннарда конструкцияләрне сүтү һәм яңадан җыю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре чыга торган һәм бина фундаментлары белән кисешкән урыннарны герметизацияләү |
| | | Потенциалларны өстәмә тигезләү системасын монтажлау, шул исәптән фатирлардагы ванналарны җиргә тоташтыру |
| | | Тимер-бетон коеларны, септикларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Гидравлик сынаулар |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 3. | Җылылык белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | Җылыту приборларына бара торган тармаклы торба үткәргечләрне, стоякларны һәм көпшәләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Панель җылыту системасын алыштыру (торгызу) |
| | | Бик арматурасын, шул исәптән стояклардан фатирларга керә торган урыннарда алмаштыру |
| | | Торба үткәргечләрне һәм арматураны изоляцияләү |
| | | Һава киртәләрен, җәелү бакларын, һава җыйгычларны һәм һава чыгаргычларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Сөлге киптергечләрне (шул исәптән регистрларны) алыштыру, бик арматурасын куеп, вертикаль буйлап тоташ су бирү стоягына тоташтыру (стояклардан фатир эчендә аерылып китә торган урыннарда җайга салына торган бик краннары булмаган очракта) |
| | | Сүндерә торган арматураны һәм байпас линиясен |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | (тоташтыргыч) урнаштырып, җылыту приборларын алмаштыру (стояклардан фатир эчендәге аера торган урыннарда яба һәм җайга салына торган краннар булмаганда) |
| | | Җылыту системасы стоякаларында, веткаларында һәм боҗраларында автомат балanслау клапаннарын урнаштыру |
| | | Кайнар су әзерләү һәм бирү комплексларында җылы йөрткеч параметрлары көйләгечләрен, җылылык алмашу приборын, бойлерларны, насос җайланмаларын һәм башка җайланмаларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, кую |
| | | Гомуми файдалану урыннарында санитар-техник приборларга су килә торган сыгылмалы көпшәләрне алыштыру |
| | | Басымны арттыра торган насос җайланмаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, кую |
| | | Коммуналь ресурсларны исәпкә алу һәм җайга салу үзәкләрен урнаштыру өчен техник бүлмәләрне торгызу яки булдыру |
| | | Техник идән астында яки беренче катның идәне астында торба үткәргечләрне ремонтлаганда, алыштырганда идәннәрне куптарып алу һәм, антисептика белән эшкәртеп, яңадан җәю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре уза торган урыннарда конструкцияләрне сүтү һәм яңадан җыю |
| | | Инженерлык коммуникацияләре керә торган һәм бина фундаментлары белән кисешкән урыннарны герметизацияләү |
| | | Гидравлик (яки башка) сынаулар |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 4. | Газ белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | Аерылып бара торган йорт эчендәге һәм фасадтагы торба үткәргечләрне һәм стоякларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Подваллардан һәм подъездлардан газүткәргечләрне чыгару |
| | | Газүткәргечләр стоякларын алыштыру һәм аларны югыч белән янәшә урнашкан зоналардан күчерү |
| | | Ябу һәм көйләү арматурасын, шул исәптән бүлмәләрдә стояклардан көнкүреш газ приборларына бара торган |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | урыннарда алыштыру |
| | | Вентиляция системаларының һава йөри торган юлларын, вентиляция шахталарын, газ йөри торган юлларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, җылыту, герметизацияләү |
| | | Инженерлык коммуникацияләре уза торган урыннарда конструкцияләрне сүтү һәм яңадан җыю |
| | | Бүлмәләрнең газлануын тикшерү приборларын ремонтлау / урнаштыру |
| | | Гидравлик сынаулар |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 5. | Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын ремонтлау | Төп һәм керә-бүлә торган щитларны (ГРЩ, ВРУ), бүлә торган һәм төркем щитларны (катларның) демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Йорт эчендәге аера торган магистральләрне һәм тәэмин итә торган линияләрнең вертикаль өлешләрен (стоякларын) алыштыру |
| | | Фатирларның тәэмин итә торган кабель линияләрен алыштыру (фатирда электр энергиясен исәпкә алуның индивидуаль приборларын урнаштырганда) |
| | | Һәр фатир өчен саклый торган сүндергеч җайланмаларын урнаштыру |
| | | Лифтларның электр җиһазын һәм инженерлык системалары эшен тәэмин итә торган электр җиһазын ток белән тәэмин итү өчен электр челтәрләрен алыштыру, лифт җиһазы һәм янгыннан саклау системалары өчен резервны автомат кертүне ток белән тәэмин итү щитларын урнаштыру |
| | | Домофон һәм антенна җиһазын ток белән тәэмин итү линияләрен алыштыру, монтажлау |
| | | Гомуми файдалану урыннарында яктырту приборларын алыштыру, яктырту приборлары белән автомат идарә итү, баскыч мәйданчыкларын, подъездларга керү урыннарын, янгын гидранты күрсәткечен, урам күрсәткечләрен авария хәлендә яктырту системасын монтажлау |
| | | Инженерлык коммуникацияләре уза торган урыннарда конструкцияләрне сүтү һәм яңадан җыю |
| | | Электр щитының ишекләрен демонтажлау, монтажлау, |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | яңадан торгызу яки алыштыру |
| | | Гомуми файдаланудагы урыннарда янгыннан автомат саклау системаларын демонтажлау, монтажлау, яңадан торгызу яки алыштыру (зарурлыгы техник тикшергәндә һәм проектын төзегәндә билгеләнә) |
| | | Гомуми файдалану урыннарында кабель линияләрен, сүндергечләрне, рубильникларны, штепсельләрне, патроннарны, розеткаларны һ.б. демонтажлау, монтажлау |
| | | Җир белән тоташтыру чыбыклары контурын демонтажлау, монтажлау, яңадан булдыру, урнаштыру |
| | | Потенциалларны өстәмә тигезләү системасын монтажлау, шул исәптән фатирлардагы ванналарны җиргә тоташтыру |
| | | Эшләтеп җибәрү эшләрен башкару |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 6. | Лифтларны ремонтлау, алыштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок урыннарын ремонтлау | Таможня берлеге комиссиясенең 2011 елның 18 октябрендәге 824 номерлы карары белән расланган Таможня берлегенең «Лифтларның куркынычсызлыгы» дигән 011/2011 номерлы ТР ТС техник регламентының 6 статьясы нигезендә хезмәт итү өчен билгеләнгән срок дәвамында хезмәт күрсәткән лифтның яраклылыгын бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә файдалану өчен яраксыз дип танылган лифтны демонтажлау, монтажлау, алыштыру, модернизацияләү |
| | | Лифт шахталарын ремонтлау, өстәмә куелган лифт шахталарын алыштыру |
| | | Лифт шахталарының һәм машина урынының яктырткычын ремонтлау |
| | | Машина урыннарын ремонтлау |
| | | Машина урыннарының ишекләрен ремонтлау яки алыштыру |
| | | Лифт җиһазының автоматлаштыру һәм диспетчерлаштыру элементларын ремонтлау, алыштыру, урнаштыру |
| | | Лифтны тәэмин итү кабельләрен алыштыру һәм резервны автомат кертү җайланмасын урнаштыру |
| | | Машина бүлмәсендә җиһазны алыштыру |
| | | Лифт җиһазы чыбыкларын җир белән тоташтыру |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | контурын демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Эшләтеп җибәрү эшләрен башкару |
| | | Монтажланган җиһазка тулы техник тикшерү үткәрү һәм лифтның Таможня берлеге комиссиясенең 2011 елның 18 октябрендәге 824 нче карары белән расланган Таможня берлегенең «Лифтлар куркыныч-сызлыгы» дигән 011/2011 нче техник регламенты таләпләренә туры килүе турында декларация алу |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган конструк-цияләренең һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 7. | Түбәне ремонтлау | Атламалык системасын, рәшәткәне (контррәшәткәне) демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, көйчәйтү |
| | | Түбәнең агач конструкцияләрен уттан һәм биологик зыян килүдән саклау |
| | | Температура һәм дымлылык режимын нормаль-ләштерү эшләре (карниз, һава суыргыч ерыкларын, тартмаларын һ.б. урнаштыру) |
| | | Чардак түшәмәсенең агач һәм тимер-бетон конструкцияләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, көчәйтү |
| | | Чардакка һәм түбәгә менә (төшә) торган баскычларны, чардак тәрәзәләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру |
| | | Куркынычсызлык элементларын (түбә баскычларын, түбә күперчекләрен, саклану арканын, ыргакларны) демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Түбә өслегең алыштыру |
| | | Тоташтыргычны демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Чорма түшәмәсен җылыту |
| | | Чорма түшәмәсен демонтажлау, монтажлау, торгызу, аны судан һәм пардан изоляцияләү |
| | | Түшәмә плиталарын демонтажлау, монтажлау, торгызу, җылыту |
| | | Түбәнең тышкы һәм эчке су чыгару системаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру |
| | | Тәрәзәләрне, ишекләрне, люкларны алыштырып, |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | түбәгә чыга торган урыннарны демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Парапетлар, брандмауэрлар, өскормалар капламаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Парапет, карниз плитәләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Яшеннән саклау һәм җиргә тоташтыру җайланмаларын, парапет рәшәткәләрен, киртәләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Кәрнизнең каплап куйгычын урнаштыру |
| | | Түбә киртәләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, алмаштыру, урнаштыру |
| | | Вентиляция системаларының һава йөри торган юлларын, вентиляция шахталарын, газ йөри торган юлларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, җылыту, герметизацияләү |
| | | Чүп торбалары дефлекторларын алыштыру |
| | | Вентиляция системаларының һава йөрткечгечләре, вентиляция шахталары, газ юллары җиллекләренә (кошлардан) саклый торган сетка кую |
| | | Вентиляция системаларының һава йөрткечгечләре, вентиляция шахталары, газ юлларының баш өлешләрендәге зонтларны алыштыру, кую |
| | | Түбәдә урнашкан лифт шахталарының конструктив элементларын (шул исәптән герметик җөйләрне) демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Югары катлардагы балконнарның, лоджийларның чыгынтыларның өслекләрен, вентиляция системаларының һава йөрткечгечләре, вентиляция шахталары, газ юлларының бетон өслекләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Җылыткыч куеп һәм түбә капламасыннан читкә чыгарып, канализация торбасының суыра торган өлешендәге пычрак суларны бетерү торбасын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру |
| | | Җылытылмый торган чорманың инженерлык коммуникацияләрен җылыту |
| | | Кар тоткарлагычларны демонтажлау, монтажлау, урнаштыру |
| | | Чормада ятма юллыкларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Чорма җиллекләрендә фасад диварлары периметрлары буенча рәшәткәләр кую |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | Түбә аэраторын урнаштыру |
| | | Металлдан эшләнгән янгыч сүндерү баскычларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру һәм аларны алга таба буяу |
| | | Һава суыра торган атчык тартмалары поддоннарын демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган конструкцияләрнең технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 8. | Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау. | Подвалда бетон юлларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, җәю |
| | | Беренче кат идәненең өрлекләрен һәм түшәмәләрен алыштыру яки көчәйтү |
| | | Подвал бүлмәләре ягыннан беренче кат идәне түшәмәләрен җылыту |
| | | Подвалның тимер-бетон, агач конструкцияләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, көчәйтү һәм гидроизоляцияләү |
| | | Подвалның конструктив элементларын антисептика белән эшкәртү |
| | | Коммуналь ресурсларны исәпкә алу һәм җайга салу үзәкләрен урнаштыру өчен техник бүлмәләрне торгызу яки булдыру |
| | | Подвал тәрәзәләрен, приямкаларны, подвалга төшү урыннарын һәм подвалга керү ишекләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру |
| | | Җылытылган, ачыла торган тәрәзә капкачлары белән жалюзи рәшәткәләрен куеп, подвалны җилләтү өчен җиллекләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу, кую яки 1 нче катның идәненнән югары итеп полипропилен торбалар белән чыгару |
| | | Дренаж системасын демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Подвалга төшү урыны стеналарын җылыту |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган конструкцияләрнең технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 9. | Фасадны ремонтлау | Штукатур эшләрен кертеп, тышкы стеналарны демонтажлау, монтажлау, торгызу (көчәйтүне кертеп) |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | Диварның кирпечен демонтажлау, монтажлау, торгызу (көчәйтүне кертеп), өлешчә яңадан салу |
| | | Ярыкларга махсус состав кертү |
| | | Тәрәзә уемнарын алыштыру |
| | | Тышлый торган плитканы демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Кирпечтән һәм тышлый торган керамик плиткадан эшләнгән фасадның тышкы диварларын юу |
| | | Фасадның архитектура элементларын демонтажлау, монтажлау, торгызу (көчәйтүне кертеп) |
| | | Фасадның диварларын буяу |
| | | Цокольне демонтажлау, монтажлау, торгызу (көчәйтүне кертеп), җылыту, гидрофобизаторлы составлар белән эшкәртү |
| | | Эре блоклы һәм эре панельле биналардагы стена панельләренең (шул исәптән лифт урыннарының тоташкан стена панельләренең) горизонталь һәм вертикаль тоташкан урыннарын (герметик җөйләрен) демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Деформацияләнгән җөйләрне демонтажлау, монтажлау, яңадан торгызу |
| | | Тәрәзә һәм балкон пыялаларын алыштыру (гомуми мөлкәт составында) |
| | | Тәрәзә рамнарын, урам яктагы тәрәзә төпләрен буяу |
| | | Урам яктагы тәрәзә төпләрен, балкон плитәләренең чыгынтыларын алыштыру |
| | | Подъездларга керү, чүп камераларына керү ишекләрен алыштыру |
| | | Халыкның аз хәрәкәтләнә торган төркемнәре файдалана алу чараларын исәпкә алып, керү урыны төркемнәрен демонтажлау, монтажлау, торгызу (ныгытуны кертеп) яки урнаштыру |
| | | Гидроизоляциясен яңадан эшләп, ачык балконнарның һәм лоджияләрнең киртә һәм терәк конструкцияләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Ачык балконнар плитәләренең авыш цемент-ком тигезләгечен урнаштыру |
| | | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм, күпфатирлы йорттагы тиешле сыйфатта булмаган уртак мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан озаграк |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | туктатып торып хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 11 пунктындагы «в» пунктчасы таләпләрен исәпкә алып, җылытылган, ачыла торган тәрәзә капкачлары белән жалюзи рәшәткәләрен куеп, подвалны җиләтү өчен җиллекләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу, кую яки 1 нче катның идәненнән югары итеп полипропилен торбалар белән чыгару |
| | | Отмостканы демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Суны кире кайтара торган лотокны демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Гомуми файдаланудагы урыннарда тәрәзәләрне алыштыру |
| | | Йорт билгесен демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Чорма җиллекләрендә фасад диварлары периметрлары буенча рәшәткәләрне демонтажлау, монтажлау, торгызу, кую |
| | | Янгын сүндерү баскычларын демонтажлау, монтажлау, торгызу, урнаштыру |
| | | Подвал тәрәзәләрен, приямкаларны, подвалга төшү урыннарын һәм подвалга керү ишекләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру |
| | | Тышкы су агып төшә торган торбаларны демонтажлау, монтажлау, торгызу, алыштыру, урнаштыру |
| | | Югары катлардагы балконнар, лоджийлар чыгынтылары капламаларын демонтажлау, монтажлау, торгызу яки алыштыру |
| | | Подъездларга, подвалларга керү ишекләре өстендәге козырёкларны демонтажлау, монтажлау, яңадан торгызу, алыштыру, эшләү |
| | | Лифт шахталарының тышкы стеналарны демонтажлау, монтажлау, яңадан торгызу (ныгытуны кертеп) |
| | | Җылыткычны демонтажлау, монтажлау, яңадан торгызу, урнаштыру |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган конструкцияләрнең технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |
| 10. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | Фундаментны вертикаль һәм / яки горизонталь гидроизоляцияләү |
| | | Отмостканы демонтажлау, монтажлау, торгызу |
| | | Подвалның конструктив элементларын антисептика белән эшкәртү |
| | | Фундаментны ныгыту, яңадан торгызу |
| | | Фундамент элементларының тоташкан урыннарын, җөйләрен, ярыкларын каплау һәм тыгызлау, аларга махсус состав кертү |
| | | Приямкаларны, подвалга керү ишекләрен демонтажлау, монтажлау, торгызу (ныгытуны кертеп) |
| | | Инженерлык коммуникацияләренең бина фундаменты белән кисешкән урыннарын герметизацияләү |
| | | Күпфатирлы йортның төзелеш проекты буенча куелган, ремонтлана (алмаштырыла) торган конструкцияләрнең технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында сүтелгән яисә җимерелгән мөлкәтне урнаштыру һәм (яки) яңадан урнаштыру |

Искәрмәләр:

1. Күпфатирлы йорттагы төзелеш конструкцияләренең һәм инженерлык системаларының кайбер элементларына капиталь ремонт үткәрүнең иң чик кыйммәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән раслана.

2. Күпфатирлы йортның конструктив элементларын һәм инженерлык системаларын чираттагы капиталь ремонтны үткәргәнгә кадәр нәтиҗәле файдалануның норматив сроклары (норматив ремонтара сроклары) СССРның Төзелеш эшләре буенча дәүләт комитеты каршындагы Архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча дәүләт комитетының «Архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча дәүләт комитетының «Торак биналарны, коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны реконструкцияләүне, ремонтлауны һәм аларга техник хезмәт күрсәтүне оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә» ведомство төзелеш нормаларын раслау турында» 1988 елның 23 ноябрендәге 312 номерлы боерыгы белән расланган «Торак биналарны, коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны реконструкцияләүне, ремонтлауны һәм аларга техник хезмәт күрсәтүне оештыру һәм үткәрү турында нигезләмә» дигән ВСН 58-88(р) ведомство төзелеш нормаларында бирелә.

3. Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән күпфатирлы йортның уртак мөлкәте составындагы конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлаганда һәр конструкциянең һәм инженерлык системасының кимендә 50 проценты алмаштырыла.